КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 июль г.Казань № 592

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар турында» 2013 ел, 29 август, 614 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар турында» 2013 ел, 29 август, 614 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 11 ноябрь, 866 нчы; 2014 ел, 8 май, 304 нче; 2014 ел, 17 май, 330 нчы; 2014 ел, 26 декабрь, 1032 нче; 2016 ел, 17 февраль, 98 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 733 нче; 2018 ел, 20 март, 159 нчы; 2019 ел, 8 апрель, 274 нче; 2019 ел, 21 май, 427 нче; 2019 ел, 2 октябрь, 886 нчы; 2019 ел, 31 октябрь, 985 нче; 2019 ел, 24 декабрь, 1186 нчы; 2020 ел, 25 февраль, 140 нчы; 2020 ел, 1 апрель, 248 нче; 2020 ел, 27 май, 428 нче; 2022 ел, 31 март, 295 нче; 2022 ел, 29 сентябрь, 1045 нче; 2022 ел, 29 декабрь, 1447 нче; 2023 ел, 30 март, 380 нче; 2023 ел, 22 июнь, 741 нче; 2023 ел, 14 август, 980 нче, 2024 ел, 1 март, 109 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирүгә республика конкурсын үткәрү буенча оештыру комитеты составында:

оештыру комитеты составыннан А.Г.Барышевны чыгарырга;

оештыру комитеты составына Семенычев Аркадий Борисовичны, «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе башкарма секретаре урынбасарын, оештыру комитеты секретарен кертергә (килешү буенча);

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирү һәм алардан файдалану тәртибендә:

4.7 пунктның 4.7.2 пунктчасында:

өченче абзацта «5 мең кешедән 11 мең кешегә кадәр» сүзләрен «5 мең кешедән 12 мең кешегә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «11 мең кешедән» сүзләрен «12 мең кешедән» сүзләренә алмаштырырга;

4.9 пунктның беренче абзацында «өч елдан да иртәрәк булмаган» сүзләрен «ике елдан да иртәрәк булмаган» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин